| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2022 г.Зеленодольск № 79

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы турында

«Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесенең Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы нигезендә, җәмәгать фикер алышуларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планын расларга (карталар һәм текст өлеше кушымтада бирелә).
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге генераль планына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 19 сентябрендәге 276 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга
3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм«Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М. П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ